ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

# ПРИКАЗ

16.12.2016 № 119-од

г. Казань

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итүләре тәртибен раслау хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның һәм бүтән затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килүе турында хәбәр итүләре тәртибе хакында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге № 650 Указы нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итүләре тәртибен расларга (алга таба – Тәртип).

2. Коррупцион хокук бозуларны кисәтү өчен җаваплы затка түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетындагы дәүләт граждан хезмәткәрләрен, шулай ук хезмәт контрактлары төзегәндә гражданнарны да әлеге боерык белән таныштыруны;

Тәртипне Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының мәгълүмат стендында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Идарәнең рәсми сайтындагы «Коррупциягә каршы тору» бүлегендә урнаштырыруны.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис

И.Х. Әюпова

Татарстан Республикасының
Архив эше буенча
дәүләт комитетының
16.12.2016 № 113 -од
боергы белән
РАСЛАНДЫ

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында
дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итүләре
тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – Дәүләт комитеты, граждан хезмәткәрләре) Дәүләт комитеты рәисе үзләренә карата эшкә яллаучы булганда аның вәкиленә дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү процедурасын регламентлый.

2. Хәбәр итү вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында әлеге Тәртип кушымтасында китерелгән форма буенча граждан хезмәткәре тарафыннан язма рәвештә төзелә (алга таба – хәбәрнамә) һәм Дәүләт комитеты рәисенә җибәрелә.

3. Дәүләт комитеты рәисе өч эш көне эчендә алдан карау өчен хәбәрнамәне коррупцион һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) җибәрә.

4. Хәбәрнамәне алдан карау барышында җаваплы зат хәбәрнамә җибәргән граждан хезмәткәреннән анда бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмалар алырга, дәүләт хакимияте органнарына, бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга билгеләнгән тәртиптә гарызнамәләр җибәрүне китереп чыгарырга хокуклы.

5. Алдан карау нәтиҗәләре буенча җаваплы зат дәлилләнгән бәяләмә әзерли. Алдан карау барышында алынган хәбәрнамә, бәяләмә һәм материаллар алынганнан соң җиде эш көне эчендә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә (алга таба – Комиссия) тапшырыла.

6. Әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән гарызнамәләр җибәрелгән очракта, хәбәрнамә, бәяләмә һәм башка материаллар җаваплы зат тарафыннан хәбәрнамә алынганнан соң 45 көн эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Күрсәтелгән срок Комиссия рәисе тарафыннан 30 көннән дә артмаган чорга озайтылырга мөмкин.

7. Хәбәрнамә, бәяләмә һәм башка материаллар Комиссия тарафыннан Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында Идарә боерыгы белән расланган нигезләмә нигезендә карала.

16.12.2016 № 119 -од
Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерүе мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итүләре тәртибенә кушымта

Татарстан Республикасының
Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисенә
______________________________
(дәүләт хезмәткәренең Ф. Ис. Ат. ис., вазыйфасы, структур бүлекчә)

Дәүләт вазыйфаларын үтәгәндә
мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында
хәбәрнамә

Дәүләт вазыйфаларын үтәгәндә минем мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуым барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәгенең астына сызарга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килү өчен нигез булган хәлләр: ______________________________________________________________________________.

Үтәлүләре барышында шәхси кызыксыну йогынты ясый торган һәм йогынты ясарга мөмкин булган вазыйфаи бурычлар:
______________________________________________________________________________.

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар:
_______________________________________________________________________.

Әлеге хәбәрнамәне караганда Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим/нияләмим (кирәгенең астына сызарга).

"___"________ 20___ел ________________ ________________________________
(хәбәрнамә җибәргән затның имзасы) (имзасы расшифровкасы)